**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

20.09.2024 № 320

**Татарстан Республикасының Баш операцион үзәген төзү турында**

1. 2024 елда Казан шәһәрендә БРИКС дәүләтләре башлыклары очрашуы кысаларында чараларны уздыру чорында аерым мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен, аның җитәкчесе итеп Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын билгеләп, Татарстан Республикасының Баш операцион үзәген төзергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасының Баш операцион үзәге турында нигезләмәне һәм аның составын расларга;

әлеге боерыкны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**